СОВЕТ ШАДЧИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение Карар

№ 7-7 «03» март 2016 ел

2016 елның 28 февралендә референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2015 елның 1 мартында референдум нәтиҗәләре нигезендә: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән хакимият чикләрендә халыкка электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, канализация, ягулык белән тәэмин итүне оештыру.
Ямаш авылында су алу башнясын койма белән тотып алу - 16,0 мең сум.

- Җирлек халкы өчен массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын оештыру, шул исәптән гражданнарның җәмәгать су объектларына һәм аларның ярларына бушлай керүен тәэмин итү:
Ямаш авылында чишмәләрне төзекләндерү - 13,0 мең сум.

- Ял вакытын оештыру һәм торак пунктларында мәдәни оешмалар хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру:

Юкәче, Иске Мочалкино, Яңа Мочалкино авылында авыл клубларын ремонтлау - 44,8 мең сум.

- - Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
Шәдче торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау:
Муса Җәлил урамы – 250 м.
Мәктәп урамы – 1100 м.
Вахит торак пунктында:
Татарстан урамы – 300 м.
Габдулла Тукай урамы – 400 м.
Вак таш өстәү, грейдер белән тигезләү - 68,6 мең сум
-- «Әйе» «Юк»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2016 елның 29 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 55 номерлы карарын теркәргә.
2. Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану юнәлешләрен һәм күләмнәрен кушымта буенча билгеләргә.
3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /В.В.Шрыков /

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге Советының 3 март, 2016 ел, № 7-7 карарына
КУШЫМТА

Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану

юнәлешләре һәм күләмнәре

| N т/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең атамасы | Шул исәптән планлаштырылган чаралар | чараларны гамәлгә ашыруга акча күләме, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән хакимият чикләрендә халыкка электр, җылылык, газ һәм су белән тәэмин итү, канализация, ягулык белән тәэмин итүне оештыру | Ямаш авылында су алу башнясын койма белән тотып алу | 16,0 |
| 2. | Җирлек халкы өчен массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын оештыру, шул исәптән гражданнарның җәмәгать су объектларына һәм аларның ярларына бушлай керүен тәэмин итү | Ямаш авылында чишмәләрне төзекләндерү | 13,0 |
| 3. | Ял вакытын оештыру һәм торак пунктларында мәдәни оешмалар хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру | Юкәче, Иске Мочалкино, Яңа Мочалкино авылында авыл клубларын ремонтлау | 44,8 |
| 4. | Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге | Шәдче торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау: Муса Җәлил урамы – 250 м. Мәктәп урамы – 1100 м. | 68,6 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | Вахит торак пунктында:<br>Татарстан урамы – 300 м.<br>Габдулла Тукай урамы – 400 м.<br>Вак таш өстәү, грейдер белән тигезләү | |
| Барлыгы | | | 142,4 |